ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2025 Олы Кайбыч ав. № 515

Кадастр номеры 16:21:0110:532 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Халыкның тормыш эшчәнлегенең уңай шартларына хокукларын, җир кишәрлекләре хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең «Туристик хезмәт күрсәтү» универсаль торак зонасында (Ж-У) Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Олы Кайбыч авыл җирлеге, Чишмәле ур., 57 ж/к адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:21:0110:532 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә (кушымта).

2. Кадастр номеры 16:21:0110:532 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 25 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар ур., 7 й. адресы буенча урнашкан иҗтимагый үзәк актлар залында уздырырга.

3. Кадастр номеры 16:21:0110:532 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проектындагы материаллар (текст һәм график өлеш) белән Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар ур., 7 й., 2нче кат 209нчы кабинет адресы буенча эш көннәрендә 10.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә кадәр танышырга мөмкин.

3.1. Кадастр номеры 16:21:0110:532 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр җыю урыны итеп Татарстан Республикасы, Кайбыч

районы, Олы Кайбыч авылы,  Кояшлы бульвар ур., 7 й., 2нче кат 209нчы кабинет адресы буенча инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

- кадастр номеры 16:21:0110:532 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

- әлеге карарны Татарстан Республикасы  хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Е.Г. Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025е. 14.11.
515 номерлы карарына
кушымта

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРОЕКТ**

№__________

П Р И К А З Б О Е Р Ы К

«_____»______________20__

**Шартлы рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануга рөхсәт бирү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе тәкъдимнәрен исәпкә алып, боерам:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Киләчәк» яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә (Федотова Лилия Маратовнага) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең «Туристик хезмәт күрсәтү» универсаль торак зонасында (Ж-У) Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Олы Кайбыч авыл җирлеге, Чишмәле ур., 57 ж/к адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:21:0110:532 булган җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә.

2.Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итү секторына (Р.Җ.Зәйнуллинага) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару

кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенә (А.В.Ароновага) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруга җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Территорияләрне үстерү департаменты җитәкчесе** **А.И. Әхмәтҗанов**